ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 өлешендә «теркәүне» сүзеннән соң «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы,» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин итү**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен һәлакәттән коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итүче һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тәэмин итү нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 55-ТРЗ